**Укытучы:** Гарифҗанова Ләйлә Мәсхүт кызы
1нче категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы
**Тема : Синонимнар иленә сәяхәт. Уен-дәрес.**

**Максат:** 1. Синоним сүзләрне искә төшерү; синонимнарны сөйләм телендә аера һәм куллана белергә өйрәтү; үткән белемнәрне ныгыту.

2. Сөйләм һәм язма телен, фикерләү сәләтен үстерү; мөстәкыйль активлыкларын үстерү.

3. Төркемнәрдә эшләгәндә, аралаша белү, бер-береңне тыңлый белү культурасы, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү; туган телне өйрәнергә, якларга, баетырга һәм белемнәребезне киләчәк көннәргә сакларга өйрәтү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:** укучылар тел байлыкларын, фикерләү сәләтләрен үстерергә, синоним сүзләрне аера һәм сөйләмдә дөрес куллана белергә, төркемнәрдә эшләгәндә аралашу, ярдәмчеллек сыйфатларына, туган телне якларга, баетырга һәм белемнәрен киләчәк көннәргә сакларга өйрәнерләр.

**Дәрес барышы**.

***I. Оештыру моменты***.

1. Тел дигән дәрья бар,
Төбендә энҗе-мәрҗән бар,
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры калыр.

- Хәерле көн, укучылар! Мин дә сезне белем дәрьясына чумып, андагы хәзинәләрне табарга чакырам. Барыгыз да әзерме? Алай булгач, алга!

***II. Актуальләштерү.***

- Дуслар, шүрәле малае Шүркә белән сез күптән таныш инде. “Салават күпере” журналын укып, аның нинди маҗаралы хәлләргә юлыгуын да беләбез.


**Слайд № 2** **Слайд № 3**





- Менә ул беркөнне сандык тапкан бит! Бик тә ачып карыйсы килсә дә, ача алмаган. Ярдәм сорап, безнең янга килгән. Ярдәм итәбезме үзенә?
- Бик яхшы, укучылар! Сез чын дус! Синонимнарның нинди сүзләр
булуын онытткан икән бит, Шүркә. Ә сез, беләсезме соң?

**Слайд № 4**




- Афәрин! **Әйе, синонимнар** дип бер үк яки якын мәгънәле, мәгънәдәш сүзләрне атыйлар. Мәсәлән, батыр, кыю; шаулый, гөрли; кызу, кайнар, эссе.

**III. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

Ә хәзер тылсымлы кодны табуы да авыр булмас. Шулай бит?

**Слайд № 5**




(Укучылар  экрандагы сүзләрне укыйлар, синонимнарны табалар)

- Туган ил, ватан; сулды, шиңде; кадерле, газиз. Синонимнарны дөрес тапкан булсак, сандыкның кодын белербез. Код саны – 356. Сез булдырдыгыз!

**Слайд № 6**



- Сандык эчендә карта ята, дуслар.  Карыйк әле, нинди карта икән соң бу? Ул безне “Синонимнар иленә” сәяхәткә чакыра.

**Слайд № 7**



Безнең юлыбыз  “Ребус таулары”, “Синонимнар елгасы”, “Мәкальләр лабиринты”, “Чуалчык урман” аша үтәчәк, дуслар.

- Куркып калмассызмы? Көчегез җитәрме?
- Алайса, юлга кузгалдык. Хәерле сәгатьтә!

**Слайд № 8**




- Алда Ребус таулары. Ребус таулары артына нинди сүзләр качты икән?

Бу сүзләрне тапсак, очкычка утырып, таулар аша очарбыз.
Балдак һәм йөзек сүзләре – синонимнар. Молодцы!

**Слайд № 9**




Таулар аша очып, Чуалчык урманга килеп җиткәнбез. Нинди сынаулар әзерләп куйды икән ул безгә? Әһә, җөмләләрдә буш урыннар бар. Нинди сүзләр куярбыз анда?

- Бара торгач, ул бик арыган, йөдәгән, талчыккан.
- Кояш аны җылы нурлары белән назлаган, сөйгән, иркәләгән.
- Бу бала бөтенләй ятим, ялгыз, берүзе калган.

Укучылар, лабиринтның ни икәнен беләсез. Әмма алдыбызда гади лабиринт түгел, ә Мәкальләр лабиринты. Чыга алырбызмы? Әйдәгез, көчебезне сынап карыйк.

**Слайд № 10**




- **Татлы** тел аю биетә.
- **Тәмле** тел яз кебек, тәмсез тел көз кебек.
- **Белемле** кеше югалмас.
- **Укыган** уңар, укымаган туңар.
- **Кыюның** бәхете алдан йөрер.
- **Батыр** ут булыр, куркак юк булыр.

**Слайд № 11**




- Синонимнар елгасын кичү өчен синоним-ташлардан күпер салу да безнең өстә, дуслар. Моның өчен синоним сүзләр ярдәмгә килер. Дус-иптәш, газиз-кадерле. Менә шәп! Күпер әзер.

Шулай итеп, без барлык сынауларны үтеп, Синонимнар иленә килеп тә життек, дуслар. Карагыз әле, Шүркә ничек шатлана! Ул сезне, ял иткән арада, домино уены уйнап алырга чакыра. Чыннан да, Синонимнар иле икән бит! Доминоларына кадәр санлы түгел, синонимлы. Өлгер булуыгызны монда да күрсәтегез әле!

(Укучылар төркемнәргә бүленеп доминоларны җыя башлыйлар. Доминоның бер башына “Кем өлгер?” дип язылган, икенче ягына, мәсәлән, матур. Уен башлана, балалар матур сүзенең синонимын эзли һәм табып матур янына куя. Шул рәвешле, кайсы төркем барлык сүзләрне дә дөрес итеп табып бетерә, шул - өлгер.)

**IV. Йомгаклау.**




“Туган телеңнең серләрен өйрәнү - бөек эш ул”, - дигән татар галиме, мәгърифәтче Каюм Насыйри. Татар телендә синоним сүзләр бик күп. Алар барысы да безнең лексик байлыгыбызны тәшкил итәләр. Теле синонимнарга бай кеше үз уен ачык, төгәл әйтә ала, фикерен дөрес чагылдыра, җөмләләре кыска һәм җыйнак була. Сез дә туган телебезнең серләрен өйрәнүдән туктамагыз! Ә бүгенгә дәрес-сәяхәтебез тәмам. Игътибарыгыз һәм хезмәтегез өчен зур рәхмәт!